**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләрендәге**

**9 нчы сыйныф укучылары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан**

**IVХалыкара олимпиада биремнәре**

1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә образларны төркемнәргә бүлеп языгыз:

Төп герой;
Ярдәмче герой;
Эпизодик герой;
Әйбер образлары;
Ясалма образлар.

Әсәрдә геройларның тышкы һәм эчке матурлыгын сурәтләү барышында автор нинди образлардан файдалана? Җавабыгызны, әсәр сюжетына нигезләнеп, 7-8 җөмлә белән төгәл итеп языгыз (20 балл).

2. З.Бигиев иҗат иткән “Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә” әсәрендә мәгърифәтчелек әдәбиятына хас үзенчәлекләрне билгеләгез, үз фикерегезне әсәр мисалында раслап барыгыз (20 балл).

3. *Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман, / Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман!* (Г.Тукай). Әлеге шигырь юлларына таянып, 100 сүздән дә ким булмаган күләмдә инша языгыз (20 балл).

4. Түбәндә тәкъдим ителгән аңлатмаларга нигезләнеп һәм җавап өлешендә күрсәтелгән сүзне истә тотып, туры килә торган фразеологик әйтелмәләрне языгыз. **(**Һәр дөрес җавап - 2 балл; барлыгы 10 балл).

*1) уңган кеше турында*

________________*калганнардан*___________________________________

*2) физик яктан көчле кеше турында*

_________________*тимер*_________________________________________

*3) матур сүзле, оста телле кеше турында*

__________*кесәгә*_______________________________________________

*4) биргән вәгъдәсенә туры калучы, һәр әйткән сүзен үлчәп сөйләшүче*

________*хуҗа*________________________________________________

*5) тәҗрибәле, дөнья күргән кеше турында*

______________*теше*_________________________________________

5. Түбәндә бирелгән сүз парларына өчәр хәреф өстәп, сүзләр языгыз. Беренче сүзнең ахырына куелган хәрефләр икенче сүзнең башында булырга тиеш. **(**Һәр дөрес җавап - 1 балл; барлыгы 5 балл).

БАГ . . . - . . . ЛИЗ

АЛД . . .  -  . . . МЛЫК
БЫЛ . . . -  . . . МА
ИГЪ . . .  –  . . . ДЫШ
ДӘФ . . . - . . . ТИП

6 . *Сау бул инде, хуш, бәхил бул,*
*И минем торган җирем.* (Г.Тукай) шигъри юлларында аерып күрсәтелгән сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз. Мондый сүзләрне ничек атап йөртәләр? Әлеге тел күренеше турында белгәннәрегезне языгыз. (Барлыгы 10 балл).

7. Өзекне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез (Һәр бирем - 3 балл; барлыгы 15 балл).

*1) Исәнме, уртак Анабыз авыл! 2) Без барыбыз да синең җылы кочагыңда тәгәрәшеп үстек, кеше булдык. 3) Син һәркайсыбызга шәфкатьле әни булдың. 4) Беребезне дә какмадың, сукмадың, егылганда күтәреп алдың, елаганда йомшак кулларың белән күз яшьләребезне сөрттең, юаттың, гомер сукмагыннан атлаганда ялгышсак, туры юлга керттең. 5) Син безне сабырлыкка, үз көчең белән көн күрергә, башкаларга ярдәм кулы сузарга өйрәттең. 6) Синең төп тәрбия ысулың хезмәт иде, ул хәзер дә шулай булып кала. 7) Аягыбызга басуга, ук бездә бәпкә-чебешләрне саклау һәм ашату, көтүдән мал-туарны алып кайту, бакчада чүп утау кебек шөгыльләр аша җаваплылык тойгысы тәрбияләдең <...> бары тик үз көчеңне салып кына тормыш итәргә мөмкин икәнлегенә төшендердең. 8) Барысы өчен дә рәхмәт сиңа, уртак әниебез!   (Ф. Садриев)*

1. 7 нче җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз.

2. Өзектән *мәрхәмәтле* сүзенең синонимын язып алыгыз.

3. 1-5 нче җөмләләрдән шарт фигыльләрне язып алыгыз.

4. Өзектән рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне язып алыгыз.

5. Эндәш сүзләр кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.